# Х. Мөҗәй иҗатында сугыш чынбарлыгының гәүдәләнеше.

Ватан өчен көрәш кырларында сыналган әлеге бай рухи җегәр, әхлакый тәҗрибә бүген дә фронтовик әдипләр иҗатында дәвам иттерелеп, яңа буын шагыйрьләренә мирас буларак тапшырыла. Аларның әсәрләрендә җитди проблемалар тирән чагылыш таба, сугышчанлык һәм батырлык традицяләре дәвам итә. Дошманның ут нокталарын үз гәүдәләре белән каплаган каһарманнар турында без – яшь буын белергә тиеш. Үткәнен белмәгәннең, киләчәге юк! Бары, шушы мул, рәхәт тормышыбызның күп кан коюлар аша төзелгәнен киләчәк буыннарга аңлаткан очракта гына, без хәзерге чорыбызның рәхәтен, кадерен белеп яши алырбыз. Бу – бүгенге көндә иң актуаль проблема. Гомерен һәм иҗади талантын Ватан өчен корбан иткән каһарман язучылар милләтебезнең горурлыгы, туачак буыннар өчен туган илгә тугрылык үрнәге булып тора. Аның хакындагы истәлекләрне, батырлыгының иҗади ядкәрләрен кадерләп саклау – безнең изге бурычыбыз.

Минем фәнни эшем Х. Мөҗәйнең Дахау төрмәсендә алып барган политик эшчәнлеге, Татар Самсоны дигән бөек исемгә лаек булуы, чын кешелек сыйфатларына ия булган, үлемне җиңгән, кара фашист тоткынлыгында соңгы көннәрен яшәвен белеп торучы поэзиянең куркусыз батыры, башкорт шагыйре дип йөртелгән шәхес турында. Фашистларның рәхимсез кыйнауларына, иң каты җәзаларына түзгән, тик иленә, Ватанына биргән изге антына тугры калган герой – Х. Мөҗәй хакында.

Х. Мөҗәй иҗаты турында мәгълүмат күп түгел. Аның исеме әдәбиятта аз күренә. Шулай да Х. Мөҗәйнең Бөек Ватан сугышы кырларында һәм тоткынлыкта күрсәткән батырлыгын өйрәнүгә, эзләү һәм пропагандалауга бөтен иҗат көчен юнәлткән әдипләребез бар. Бу өлкәдә бигрәк тә фронтовик әдип Самат Шакирның тырышлыгы зур. Документаль нигездә язылган әсәрләре Х. Мөҗәй кылган батырлыкның моңарчы мәгълүм булмаган ничәмә-ничә сәхифәләрен ачты. Ул аның сугышта язган көндәлек-дәфтәрен “Сугыш язмалары” исемле китапка теркәп чыгара.

Кем соң ул, нинди кеше булган – сугыш азагында йөзләгән офицер һәм меңләгән тоткыннарны оештырып азатлыкка өндәгән һәм 1941 нче елда ук инде Гитлер фашизмының киләчәктә тар- мар ителәчәген алдан күргән бу шәхес? Үзе турында шагыйрь бик хаклы рәвештә:

Көлә беләм, шаулап җырлый беләм,

Көрәшләрдә күңел ямь таба.

Күз алдымда каты үлем күрәм

Җиңә беләм,җиңү мәртәбә.

дип белдерде.

Х. Мөҗәй күп кенә әсәрләрен Урта Азиядә, хәрби хезмәттә чакта иҗат иткән. Кайбер шигырьләренә композиторлар көй язган. 1939-1941 нче елларда Х. Мөҗәй «Олы юлдан» романын яза башлый. Ул бу романында туган илендә барган авыр көрәшне, совет властен яклап сугышкан көрәшчеләрнең батырлыгын сурәтли. Автор данлы еллар, утлы сугыш белән үткән, көрәшкә багышланган, ил дип янган татар интеллигенциясенең шул елларда тормыш-көнкүрешен чагылдыра. Искелеккә каршы көрәшүче уңай типларны татар әдәбиятында алгы планга куеп күрсәтә. Х. Мөҗәй изүче тормышка протест, нәфрәт белдерүче геройның тирән рухи канәгатьсезлек һәм каршылыклар аша, үз максатына, бигрәк тә шәхси ирегенә ашкынуын Зәки образы аша гәүдәләндерде.

Х. Мөҗәйнең әсәрләрендәге геройлар, әсәрдән- әсәргә төрле яклары белән ачыла барып, бай рухи дөньялы, тирән кичерешле, кешелекле һәм нык ихтыярлы, көрәшчән табигатьле чын кеше булып килеп баса. Ул патриотизм темасын чишүгә алдынгы рус һәм татар әдәбиятының, күренекле совет язучыларының традициясен дәвам иттерә. Х. Мөҗәй Бөек Ватан сугышында катнашуны үзенең намус эше итеп, горурлык итеп саный. Ул шулай ук батыр йөрәкле иптәшләре өчен дә горурлана. Үзенең «Пулеметчы кыз» шигырендә сугыш җирләрен дә олысының- кечесенең кулларыннан килгәнчә, немецларны юк итүгә керткән өлешләре турында яза. «Автоматчы » шигыре тирән лирика белән сугарылган. Шигырьдә сурәтләнгән батыр автоматчының кирәк һәм

тиешле вакытта дошман явы өстенә ыргылырга торучы, сугышның дошман явы өстенә ыргылырга торуы, сугышның дәһшәтле сулышы, батыр совет сугышчыларының Ватанга изге мөнәсәбәте гәүдәләнә. Үзенең «Шакир» хикәясендә гади генә сугышка китүче солдат образы аша барлык солдатларның да аерылышкач, әйтелмичә калган уй-хисләрен, тирән кичерешләрен тасвирлый. Ләкин Шакир нинди генә батырлык эшләсә дә азсына, һаман бер үк сүзләрне кабатлый: «Командирга да куңелле булыр, Зөһрә дә шатланыр, миңа да шәп». Яндыргыч шешәләр ташлап, өч немец танкын  яндыруын да, ике немец солдатын әсир итеп алып кайтуын да, башка солдатларның батырлыклары белән чагыштырып һаман азсына, тагын да данлырак батырлыклар эшләү теләге белән яна. «Бүләк» шигырендә бар йөрәк җылысын, күңелендәге изге хисләрен яулыкка йөрәк рәсемен төшереп, чигеп җибәргән, сөю утларында янучы бер кызның кульяулыгы кулына килеп кергәч, хисләр дулкынына бирелеп туган бу шигырендә батыр сугышчыларның гына түгел, тылда калган хатын- кызларның, яшүсмерләрнең дә бәхетсез, авыр көннәре тасвирлана. Х. Мөҗәй гитлерчы фашистларның ерткычлыкларын, вәхшилекләрен үз күзләре белән күрә һәм үзенең иҗатында фашизмның чын йөзен фаш итә. “Сөт” хикәясендә, “Немец халкына командир һәм шагыйрь Х. Мөҗәйдән ачык хат” һәм “Каның, җаның белән түләрсең” кебек шигырьләрендә совет солдатының үлемне дә җиңеп чыгуын күрсәтә.

Иҗатының беренче чорыннан ук Х. Мөҗәй- шагыйрь- гражданин, көрәшче һәм патриот. Аның һәр әсәрендә туган җирен ихлас сөюче һәм аның җиңәчәгенә ышанучы иле белән горурланучы солдат образы тора. Ул Бөек Ватан сугышы елларының авырлыгын һәм бөтен дөнья халыкларының йөрәк авазын ул үзенең шигырьләрендә чагылдырды. Х. Мөҗәйнең иҗаты сүзенең үткенлеге, эмоциональ көче, дәртле рухы белән укучыны уйланырга мәҗбүр итә. Аның иҗатына тыныч хезмәт көне дә, матур җәйге иртә картинасы да, туган илгә мәхәббәт тә, фашизмга нәфрәт тә сыйган. Тыныч тормышның хозур гадилеге һәм сугышның куркыныч йөзе контраст алымы ярдәмендә бирелгәнлектән, аеруча көчле тәэсир итә. Тормышында булган кыйммәтләрне

ул билгеле бер тәртипкә куйган һәм анда мәхәббәт, бала хакы, якын кешеләрнең иминлеге, ата- бабаларның изге каберләре беренче урында тора! Әсәрләрендә ир- егетнең үз алдында торган сынауның җитдилеген, җаваплылыкның зурлыгын тою, рухи ныклыгы, җиңүгә ышанычы, дошманга ачуы ярылып ята. Аның максаты- өндәү, чакыру алымнары ярдәмендә халыкны сугышка, көрәшкә күтәрү, дошманга нәфрәт тәрбияләү, батырлыкны җырлау. Аның әсәрләренең күбесендә сугыш елларында җылы, саф хисләргә сусаган солдатларның иң нечкә кичерешләре дә, изге ниятләре дә гәүдәләнә.

Х. Мөҗәйнең тормыш һәм иҗат батырлыгы матур легенда булып бөтен дөньяга таралырлык. Аның шигырьләрендә чор һәм заман сулышы, илнең, халыкның йөрәк тибеше сизелә. Шагыйрь фашист тоткынлыгында патриотик эшчәнлеге белән генә түгел, ә бөтен тормыш юлы һәм ялкынлы иҗаты белән көрәшче- әдип, патриот- шагыйрь дигән исемнәрне тулысы белән аклады. Бу аның әдәбиятыбызда һәм халык күңелендәге урынын билэүче төп сыйфат.

**Файдаланылган әдәбият**


1. Шакир С. Алар сафта. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1972
2. Шакир С. Батыр сугышчы һәм шагыйрь // Совет әдәбияты.- №11.- 1963
3. Шакир С. …Безне онытмасыннар иде // Казан утлары.- № 2. - 1965
4. Бикташев В. Записи узника Дахау. - Уфа: Башкир. Книгоиздат. - 1978
5. Мөҗәй Х. Мылтыклылар.- Казан: Татарстан китап нәшрияты. -1932
6. Гарипов М. Мөҗәй батыр // Казан утлары. - № 5.- 1997
7. Шакир С. Сугыш язмалары.-Казан: Татарстан китап нәшрияты.- 1968
8. Шакир С. Үлемнән көчлерәк .-Казан: Татарстан китап нәшрияты.- 1969
9. Юзеев И. Язылмаган поэма.- Казан: Татарстан китап нәшрияты.- 1976